**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы**
**Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Карамалы авылы                    № 87                    «28» марта 2018 ел

Карамалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайты Карамалы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бу мәгълүматларны бирү тәртибе турында

«Коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 03 апрелендәге 64-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән

Карамалы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Расларга:

- Карамалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Карамалы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бу мәгълүматларны бирү тәртибен (1 нче кушымта);

- Карамалы  авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вазыйфалары, аларны биләү аларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм аларның гаиләләре әгъзаларының Карамалы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында булуы һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру исемлеге (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль

районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Карамалы авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис: А.Р.Ногманов

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге карарына
1 нче кушымта
28.03.2018 № 91

Карамалы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Карамалы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бу мәгълүматларны бирү тәртибе

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларың керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) Карамалы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бу мәгълүмәтләр бирелә, аларның гарызнамәләренә бәйле рәвештә, әгәр федераль законнар белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру һәм (яисә) аларны бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе билгеләнмәгән булса.

2. Рәсми сайтта урнаштырыла һәм гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында түбәндәге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирелә:

а) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге, мондый объектларның һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелгән;

б) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы транспорт чаралары исемлеге;

в) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәткәрнең һәм аның

хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, күрсәтелгән затларга милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында (әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән гайре) башка белешмәләр;

б) муниципаль хезмәткәрнең ире (хатыны), балаларының һәм гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси күрсәткечләре;

в) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны) һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм аралашуның башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

г) муниципаль хезмәткәрнең, аның ире (хатыны), балаларның, гаиләнең башка әгъзаларының милек хокукындагы яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

4. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларын биләгән бөтен чорда күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук аның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнашкан, һәм ел саен аларны бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көне эчендә яңартыла.

5. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында рәсми сайтта белешмәләр урнаштыру Азнакай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләре җитәкчеләре (алга таба - кадрлар хезмәте җитәкчеләре) тарафыннан тәэмин ителә.

6. Кадрлар хезмәтләре җитәкчеләре:

а) гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып өч эш көне эчендә аның турында сорау кергән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затка хәбәр итәләр;

б) гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау алынган көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән белешмәләр бирүне тәэмин итәләр, әгәр соралган белешмәләр рәсми сайтта булмаса.

7. Белешмәләр урнаштыруны тәэмин итүче кадрлар хезмәтләре җитәкчеләре рәсми сайтта керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында һәм аларны бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру хакында әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге Советының
карарына
2 нче кушымта
28.03.2018 № 87

**Карамалы авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вазыйфалары, аларны биләү аларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр һәм аларның гаиләләре әгъзаларының Карамалы авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында булуы һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Советының 2014 елның 08 августындагы 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрына кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфалары түбәндәгеләр чикләрендә:

- югары,
- баш,
- әйдәп баручылар,
- өлкән,
- муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркемнәре.

2. Муниципаль хезмәтнең коррупцион куркынычларга бәйле башка вазыйфалары буенча түбәндәгеләрне күздә тота:

- хакимият вәкиленең йә оештыру-күрсәтмә яисә административ-хуҗалык функцияләренең даими, вакытлыча яисә махсус вәкаләтләре нигезендә гамәлгә ашыру;
- гражданнарга һәм оешмаларга муниципаль хезмәтләр күрсәтү;
- контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру;
- бюджет ассигнованиеләрен, субсидияләрне, бюджетара трансфертларны бүлү турында карарлар әзерләү һәм кабул итү, шулай ук чикле ресурсны бүлү;
- муниципаль мөлкәт белән идарә итү;
- муниципаль сатып алуларны гамәлгә ашыру;
- лицензияләр һәм рөхсәт бирә торган башка документлар бирү;
- матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.